| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.06.2019 г.Казань № 484

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 10 июлендә 5688 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
2019 елның 20 июнендәге 484
номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

3.6.2 пунктчаның беренче абзацында «гаризада күрсәтелгән почта яисә электрон адреска язмача яки электрон формада» сүзләрен «почта адресы буенча язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлекнең 5.1 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр судка кадәр тәртиптә территориаль орган белгече карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – территориаль орган җитәкчесенә; учреждение белгеченә карата – Учреждение җитәкчесенә; вәкаләтле оешма белгеченә карата вәкаләтле оешма җитәкчесенә шикаять белдерергә хокуклы.

Вәкаләтле оешма, Учреждение җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр территориаль орган җитәкчесенә белдерелә.

Территориаль орган җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка тапшырыла.

Министр карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять белдерелергә мөмкин.»;

Регламентка 5 нче кушымтада:

3 пунктта «ИТП» сүзен «индивидуаль тернәкләндерү программасы (алга таба – ИТП)» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктны төшереп калдырырга;

регламентка 7 нче кушымтада 8 нче, 16 нчы пунктларны төшереп калдырырга;

Регламентка 9 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 9 нчы кушымта

Гражданинны гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлекләрендә ярымстационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында (шәһәр округында) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы территориаль органына тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

| № п/п | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документларны бирүче оешма | Документның гамәлдә булу чоры |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Шәхесне таныклаучы документ күчермәсе | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы территориаль органнары, хәрби комиссариат бүлеге, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Консуллык департаменты, гражданлык хәле актларын теркәү органы, чит дәүләтнең компетентлы органнары яисә законнар нигезендә шәхес таныклаучы документ бирүгә вәкаләтле бүтән органнар | законнар нигезендә |
| 2. | Балигълык яшенә җитмәгәннәрнең күзәтүсезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органы яисә учреждениесе вазыйфаи затының үтенеч язуы | документлар (мәгълүматлар) бирергә вәкаләтле органнары (оешмалар) | законнар нигезендә |
| 3. | Татарстан Республикасы | документлар (мәгълүматлар) | законнар |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы җитештерүдәге бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә зыян күргән хезмәткәрләр хакындагы мәгълүматларны публикацияләүне дәвам итә * | бирергә вәкаләтле органнары (оешмалар) | нигезендә |
| 4. | Социаль хезмәт күрсәтү системасына керми торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларыннан, учреждениеләрдән, эчке эшләр органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, балигълык яшенә җитмәгәннәр эшләре буенча комиссияләрдән, иҗтимагый берләшмәләрдән гадәттән тыш хәлләрдән, кораллы милләтара (этникара) низаглардан зыян күргән гражданинны ачыклау турында белешмәләр ** | документлар (мәгълүматлар) бирергә вәкаләтле органнары (оешмалар) | законнар нигезендә |
| 5. | Паспорт-виза хезмәтеннән бирелгән:<br>качак итеп тану турында яки Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыенып урын бирү турында үтенеч язуын карау турында таныклык;<br>Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турындагы гаризаны карау турында белешмә *** | документлар (мәгълүматлар) бирергә вәкаләтле органнары (оешмалар) | законнар нигезендә |
| 6. | Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерү буенча Татарстан Республикасында 2011 | федераль медик-социаль экспертиза учреждениеләре | инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең хосусый |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | елның 30 октябреннән 2015 елның 31 декабренә кадәрге чорда эшләнгән һәм бирелгән хосусый программа күчермәсе яисә инвалидларны (инвалид балаларны) тернәкләндерү яисә абилитацияләү буенча Татарстан Республикасында 2016 елның 01 гыйнварыннан бирелгән хосусый программадан өземтә күчермәсе **** | | программасында яисә инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасында билгеләнгән, социаль тернәкләндерү яисә абилитацияләү чараларын үткәрүгә мохтаҗ булу турында бәяләмәне үтәү чоры тәмамланганчыга кадәр |
| Балигълык яшенә җиткән балалар өчен өстәмә рәвештә түбәндәгеләр дә тапшырыла: | | | |
| 7. | Гражданинның, аның гаилә әгъзаларының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль хезмәтләрне түләүсез нигездә күрсәтү өчен җан башына уртача керемне билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы карары нигезендә аның җан башына уртача керемен билгеләгәндә исәпкә алына торган һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен хисаплау өчен файдаланыла торган, акча рәвешендә соңгы 12 ай эчендә алынган керемнәре булуы (булмавы) турында документлар (белешмәләр) ***** | керемнәрнең булуы (булмавы) турында документлар (белешмәләр) бирү вәкаләте бирелгән органнар (оешмалар) | законнар нигезендә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8. | Гражданинны ташламалы категориягә кертүне раслый торган документ күчермәсе ****** | вәкаләтле дәүләт хакимияте башкарма органнары, оешмалар | билгеләнгән үрнәктәге документта күрсәтелүче |

* – социаль куркыныч хәлдә булган гаиләгә һәм балигъ булмаган балаларга тапшырыла;

** – гражданнарны мохтаҗ дип тану өчен бирелә, түбәндәге шартлары булу шарты белән: гадәттән тыш хәлләрнең, кораллы милләтара (этникара) низагларның нәтиҗәләре;

*** – качак статусын алучы гражданнар һәм вакытлыча сыенып урын алучы гражданнар өчен тапшырыла;

**** – инвалидлар (инвалид балалар) өчен тапшырыла;

***** – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1101 номерлы карары (алга таба – 1101 номерлы Тәртип) белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 2.2.2 пунктының «а»-«е» пунктчаларында күрсәтелгән ташламалы категория гражданнарга тапшырылмый;

****** – ярымстационар формада социаль хезмәт күрсәтелүгә чираттан тыш, иң беренче чиратта яисә өстенлекле рәвештә кабул итүгә хокуклы ташламалы категория гражданнары өчен яисә 1101 номерлы Тәртип нигезендә бушлай нигездә социаль хезмәтләр күрсәтелү хокукына ия булган гражданнар өчен тапшырыла.»;

18 нче кушымтада 3 пунктны төшереп калдырырга;

Регламентка 20 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 6 нчы, 7 нче пунктлар өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «6. | Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерү буенча Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябреннән 2015 елның 31 декабренә кадәрге чорда эшләнгән һәм бирелгән хосусый программа күчермәсе яисә инвалидларны (инвалид балаларны) тернәкләндерү яисә абилитацияләү буенча Татарстан Республикасында 2016 елның 01 гыйнварыннан бирелгән хосусый программадан өземтә күчермәсе **** | федераль медик-социаль экспертиза учреждениеләре | инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең хосусый программасында яисә инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасында билгеләнгән, социаль тернәкләндерү яисә абилитацияләү чараларын үткәрүгә мохтаҗ булу турында |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | бәяләмәне үтәү чоры тәмамланганчыга кадәр |
| 7. | Гражданинны эшсез дип тану һәм алына торган пособие күләме турында халыкның мәшгуль хезмәте дәүләт учреждениесеннән белешмә ***** | документлар (мәгълүматлар) бирергә вәкаләтле органнары (оешмалар) | законнар нигезендә |

**** – инвалидлар (инвалид балалар) өчен таләп ителә

***** – гражданнарны мохтаҗ дип тану өчен бирелә, түбәндәге шартлары булу шарты белән: эше һәм яшәү өчен акчасы булмау;.»;

Регламентка кушымтада (белешмәлектә):

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү һәм аның үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр»;

1 нче бүлектә түбәндәге эчтәлекле юлны:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендәге социаль яклау идарәсе | (8552) 34-48-48 34-41-28 34-09-76 | 423805, Чаллы ш., Х.Туфан проспекты, 23 й. Usz.Chelny@tatar.ru | Дүшәмбе-җомга: 08.00 сәгатьтән 17.00 кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 13.00 кадәр: шимбә, якшәмбе: ял көннәре» |

киләсе редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендәге социаль яклау идарәсе | (8552) 53-60-33 | 423823, Яр Чаллы шәһәре, Кояшлы б-р, 6 й. (Яңа шәһәр, 17/11 й.) Usz.Chelny@tatar.ru | Дүшәмбе-җомга: 08.00 сәгатьтән 17.00 кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 13.00 кадәр: шимбә, якшәмбе: ял көннәре». |